Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Янсуар авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Янсуар авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

25 октябрь, 2023 ел № 3

Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлеге уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 126 номерлы (2021 елның 13 декабрендәге 35 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) Янсуар авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Янсуар авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Талкыш авылында. Гражданнар җыенын 2023 елның 10 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Кооператив урамы буенча 10 нчы йорт янында үткәрергә.

Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2024 елда Талкыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- - су белән тәэмин итү системасын ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Янсуар авылында. 2023 елның 10 ноябрендә 13.00 сәгатьтә Үзәк урамының 1 нче йортында урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында халык җыенын уздырырга.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2024 елда Янсуар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.3. Нырсуар авылында. 2023 елның 10 ноябрендә 15.00 сәгатьтә Куйбышев урамының 85 нче йорты янында халык җыенын уздырырга.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2024 елда Нырсуар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Янсуар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Янсуар авыл җирлеге башлыгы В.Н. Таланов